**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№187**
**20.01.2022**

«Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләрен финанслау үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 пунктның 4 пунктчасы, 35 статьясындагы 10 пунктның 6 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының «Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Консультация семинары үткәрү буенча «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләрен финанслау үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәткә тарифны, өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алып, 1 сәгатькә 683 сум күләмендә расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов